МИЛЛИОНЕР БАЛАЛАР
Татарстан укучылары Кырымнан баеп кайтты
> 2

БАЗАРДА КЫТЛЫК:
машина сатып алучыга киңәшләр
> 3

СУД ЗАЛЫННАН
Казан эшмәкәре чит илгә акча алып чыкканда тотылган
> 3

ПАРЛЫ БӘХЕТ
Әсән-Елга авылында яшәүче Габделхаевлар 61 ел бергә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 167 (28749) | Чәршәмбе | 17 ноябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

«БЕР БАЛА ДА УРАМДА КАЛМАС»

СТУДЕНТЛАРГА ТУЛАЙ ТОРАКНЫ БУШАТЫРГА КУШКАННАР

Казан дәүләт аграр университетында укучы егет һәм кызларның әти-әниләреннән редакциягә борчулы хат килеп иреште. Уку йортының Ферма-2 урамында урнашкан тулай торагында ремонт башланган икән. Студентлар урамда калмасмы дип борчылалар.

«Авыл хуҗалыгы институты авыл җирендә эшләүче кадрлар әзерләп чыгара. Бүген Ферма-2 урамында урнашкан тулай торакта ремонт башлана дип, балаларны чыгаралар. «Кая барасың, торырга урының бармы?» – дип кызыксынган кеше юк. Уку йорты җитәкчелеге, барлык студентларга да урын тәкъдим ителә, дип бара. Чынлыкта алай түгел. Тиз арада чыгып китегез дигән шарт куйдылар. Инде балалар мондый хәлләрне күреп, читтән торып укуга күчәбез, диләр», – дип язганнар хатта.

«Барысы да кинәт булды»

Әлеге тулай торак дүрт катлы ике корпусны үз эченә ала. Кайчан төзелгән булуын төгәл генә әйтеп бирүче булмады. Ләкин тыштан карап торышка шактый искергән бина икәнен чамалау кыен түгел. Биредә 700 студент яшәгән. Без килгәндә тулай торак тирәсендә әрле-бирле йөреп торучы студентлар шактый иде. Арада кулларына зур-зур сумкалар тотканнары да, карават, урындык ише җиһазлар күтәреп баручылары да очрады.

– Безгә сайлау мөмкинлеге бирделәр. Кемдер – фатирга, кемдер башка тулай торакка күченде. Күпчелек танышларым фатир арендалап яшәячәк. Мин дә шунда яшәргә булдым. Чөнки, беренчедән, безгә тәкъдим ителгән тулай тораклар шартлар күпкә начаррак. Икенчедән, ул уку йортына бик ерак. Өченчедән, дөресен әйткәндә, тулай торакта яшәп арыдым. Болай да моннан күченү теләгем бар иде. Яшәр өчен шартлар алай ук начар дип әйтмәс идем, мине мондагы чикләр, тулай торак куйган таләпләр туйдырды. Ә фатирда үзем генә торачакмын. Түләргә әти-әнинең мөмкинлеге бар, – диде дусты белән бергәләп сумкаларын машинага төяүче Динар.

Студентлар сүзләренә караганда, әлеге вакытта тулай торакның А корпусын тулысынча бушатканнар. Анда инде төзекләндерү эшләре башланган да. Чыннан да, бина эчендә ремонт эшләре баруына ишарәләп, каккан, суккан, нидер куптарган тавышлар ишетелә. Бинаның арткы ягында да эш кораллары, пакет, иске җиһазларны күрергә мөмкин.

Яшәр өчен урын таба алмаганнар әлегә Б корпусында яшәп тора. Аны бушатырга да бер атна вакыт бирелгән. Биредә әлегә 100ләп егет һәм кыз яши. Студентлар

Илдар Мөхәммәтҗанов

сүзләренә караганда, башка тулай тораклар 200ләп кешегә урын бирелгән.

Каршыбызга тагын ике егет очрады. Университетның икенче курсында укучы Илнур белән Айнур Зәй һәм Кама Тамагы районыннан булып чыкты. Илнур бу атна башыннан фатир арендалап яши башлаган. Айнур әлегә Казанда яшәүче апаларына барып сыенмакчы икән.

– Барысы да көтмәгәндә, кинәт булды. Шуңа күрә әти-әниләр дә, без дә югалып калдык. Уку елы башында да аны-моны әйтүче булмады, – диде Илнур. – Дөрес, якынча бер ай тирәсе элек тулай торакка ремонт керәсе икән, дигән сүзләр йөри башлады. Бинаны тулысынча сүтәләр икән, дигән имеш-мимешләр дә ишетелгәләде. Тик без аларга әллә ни әһәмият бирмәдек. Ә моннан бер атна элек җыелыш җыеп, җиде көн эчендә тулай торакны бушатырга куштылар. Павлюхин һәм Ротор урамнарындагы тулай торакларны тәкъдим иттеләр. Өлгереп калганнар шунда барып урнашты. Дөрес, анда кысан булачак, дип алдан ук кисәтеп куйдылар. Монда да бик әйбәт дип әйтеп булмый, ләкин түзмәслек түгел иде әле.

Билгеле, шартлары әллә ни булмаса да, тулай торакта яшәү күпкә арзан. Әти-әниләрнең дә күңелләре тыныч. Студентлар биредә елына 7 мең сум түләгәннәр.

– Теге тулай торакларда урын беткәч, дүрт дустым белән фатирга күчендек. Бәхеткә, моннан ерак булмаган урында фатир таптык. Аена 16 мең түлисе. Аңа өстәп, торак-коммуналь хезмәтләр өчен дә бирәсе булачак, – диде Илнур.

Беренче курс студенты Дамир да 4 дусты белән 25 мең сумга фатир арендалап тора башлаган. Тулай торакка калган әйберләрен алырга дип килгән иде.

– Әлегә менә шундый бәягә дә риза булдык, чөнки егетләргә фатир табу бик кыен. Булганнары да уку йортыннан ерак. Тапканы кыйммәт булды, әлбәттә. Ләкин тиз арада кая да булса барып урнашырга кирәк иде. Әти-әнигә түләргә авыр булмасын өчен, эшкә урнашасы булыр инде, – ди ул.

Аның белән бергә фатирга керәчәк Илдус әйтүенчә, студентларның күпчелеге я фатирга, яки туган-тумачасына күченгән.

Ахыры 2 нче биттә >

Мәктәпләр яхшырак сакланачак

Киләсе елда республикада барлык дәүләт мәктәпләрен саклауга 1 миллиард сумнан артык акча бүлеп бирелә. Республика бюджетында әлеге максатка шуның кадәр сумма каралган. Бу хакта Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллин Дәүләт Советының Бюджет, салым һәм финанс комитеты утырышында белдерде. «Шәхси сак предприятиеләренең дәүләт мәгариф оешмаларын саклавы өчен 1,1 миллиард сум каралды. Моңа кадәр бюджет проектында беренче һәм икенче категориядәге мәктәпләрне саклауга гына 340 миллион сум күздә тотылган иде. Хәзер өченче категориядәге мәктәпләр дә исәпкә алынды», – диде ул.

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

Өлкәннәр гаиләгә сыена

Татарстанда биш ел эчендә өлкән яшьтәге ялгыз 30 кеше гаиләгә сыендырылган дип хәбәр итә Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәте. «Өлкәннәрне гаиләгә сыендыру» программасы «Демография» илкүләм проекты кысасында гамәлгә ашырыла.

2019 елдан бирле республикада өлкән яшьтәгеләрне һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проекты тормышка ашырыла. Бүген бу система инде барлык районнарда бар. Моннан тыш шушы чордан бирле республикада «Өлкәннәрне карау мәктәпләре» эшләп килә. Алар барлык шәһәрләр һәм районнарда социаль хезмәт күрсәтү үзәкләрендә оештырылган. Узган ел мондый мәктәпләрдә 1,7 меңнән артык өлкән кешенең туганнары белем алган. Быел тагын 1,9 мең чамасы кеше каты авырулы сырхауларны карау буенча кирәкле күнекмәләр үзләштергән.

Казан – өченче

Россия шәһәрләрендә яшәүчеләрнең һава, су, азык-төлек, шулай ук чүп чыгаруның сыйфаты буенча экологик вазгыятьне ничек бәяләүләре өйрәнелгән. Сораштыру нәтиҗәләре шул бер үк шәһәрләрнең бер күрсәткеч буенча – алда, икенчесе буенча артта баруын күрсәткән. «Российская газета» үткәргән тикшеренүдә халык саны 500 меңнән артык булган шәһәрләрдән барлыгы 31700 кеше катнашкан.

Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Төмәндә яшәүчеләр шәһәр экологиясенең иң яхшы булуын белдергән. Краснодар икенче урынга чыккан. Казан – өченче: шәһәрдә яшәүчеләрнең 72 процентының экологиядән канәгать булуы ачыкланган. Һава, шулай ук чүп чыгаруның сыйфаты югары бәяләнгән.

Чаллы исә чүп буенча – икенче (3,3 балл җыйган) һәм суның сыйфаты буенча – өченче урында (3,4 балл). Шәһәр халкының 68 проценты экологияне әйбәт дип саный икән.

Сәрхуш килеш утырма

Татарстанда яшәүчеләрнең чама белән 40 процентының рульгә сәрхуш хәлдә утырганы бар икән. Бу хакта, сораштыру нәтиҗәләренә таянып, «Дром» автомобиль порталында хәбәр ителә. Шул ук вакытта республикада һәр өч кешенең берсе машинасын салган баштан идарә итү очрагының күптән булганын әйткән. Сораштыруда катнашучыларның 3 проценты рульгә исерек хәлдә әледән-әле утыргалап алуын күрсәткән. 7 проценты, соңгы елларда 1–2 тапкыр шундый очрак булгандыр, дип җавап биргән.

Россия буенча автомобильчеләрнең уртача 39 проценты шундый «гөнаһ»ка юл куя икән. Якутиядә, Хакасия һәм Бурятиядә исерек килеш машина йөртү очраклары башка җирләрдәгедән күбрәк булып чыккан. Ә менә Санкт-Петербург һәм Пермь краенда исерек йөртүчеләр кайдагыга караганда да азрак. Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, бу төбәкләрдә автомобильчеләрнең 70 проценты рульгә утырыр алдыннан беркайчан да хәмергә үрелмәгән.

Актуаль тема

Җир шарын үзгәрткән «туган көн»

Бүген – коронавирусның 2 еллыгы. 17 ноябрь чирнең «туган көне» санала, ди. Ике ел эчендә кечкенә генә вирус бөртеге шактый тәҗрибә туплап өлгерде: кешеләргә шулкадәр тиз ияләште, пандемия дәрәҗәсенә җитте, күп илләрнең сәяси, икътисади, социаль тотрыклылыгын җимерде, миллионлаган кешенең гомерләрен өзде.

Башлангыч чор

2019 елның 17 ноябрендә коронавирус инфекциясен йоктырган беренче кеше теркәлә. Ул Кытайдагы Хубэй провинциясеннән 55 яшьлек ир-ат булып чыга. Шул ук елның ноябрендә тагын 9 чирле ачыклана. Әмма боларның кайсы инфекцияне алданрак йоктырганы билгеле түгел, берсе дә «нуленче сырхау» булып исәпләнми.

Мәгълүмат чаралары коронавирус турында 2019 елның декабрь аенда шаулый башлады. Авыру таралу хакында беренче хәбәрләр 31 декабрьгә карый. «ВТ» исә бу чир турында тәүге тапкыр нәкъ бер айдан соң – 31 гыйнварда язды. Бу вакытта «кайгыруыбыз урынлымы?» дигән сорауга җавап эзләп, Азия илләрендәге милләттәшләребез белән элемтәгә кергән идек. Әллә ни куркыныч тоелмаган ул вакытта.

Бер әңгәмәдәшебез Сөембикә: «Россиядәге мәгълүмат чаралары үзләре үк кешедә паника тудыра. Имеш, халыкка илдән китәргә киңәш ителгән смслар юллаганнар, гомуми эвакуация игълан ителгән. Бездә андый хәбәр юк. Кытай зур. Бәлки, вирус чыккан Хубэй провинциясендә шулайдыр, ишетмәдем», – дигән.

Ике елда нәрсә үзгәрде? Коронавирусның кеше организмына гына түгел, көндәлек тормышка да йогынтысы зур булды. Телебезгә «ковид», «корона», «локдаун», «санитайзер», «ковид-диссидент», «үзизоляция» кебек сүзләр керде. Вирус «онлайн»лы, «дистант»лы тормышка ияләштерде. «Зум»да туган көннәр, киңәшмәләр, очрашулар, кичәләр, концертлар оештырылды.

Бер караганда, коронавируссыз тормышның нинди икәне дә онытылды бугай инде. Әмма ул чорга кайтасы килү теләге һич кенә дә кимемәде.

«ВТ» хәбәрчесе белән Кытайда чагында аралашкан Балтач егете Рүзәл Мөхәммәдиев ике ел элек әйтелгән сүзләрен көлеп искә ала хәзер. Егет: «Кытай өчен мондый вирус яңалык түгел. 2003, 2008 елларда да биредә вируслы авыру очрагы булган инде. Кытай моннан да котылу юлын табачак», – дип өметләнгән ул вакытта.

Чир таралу алганчы, Татарстанга кайтып өлгерә ул. Кытайда калган иптәшләре белән һәрдаим элемтәдә торган. Хәзер дә аралашып, андагы вазгыятьне белешеп тора.

– Кытай бу афәтне җиңәчәк, дигән сүзләремнән кире кайтмыйм анысы. Вирус бар-барын, әмма аның кешедән кешегә күчмәве, авыручылар саны кимү буенча Кытай чирне җиңде инде. Ил эчендә юк ул, читтән алып керсәләр генә. Анда барысы да бик катгый булды бит. Әйтик, берәр шәһәрдә инфекция табыла икән, шундук кала ябыла, анда берәү дә керми, аны ачмыйлар. Бу яктан барысы да җитди, – ди Рүзәл. – Кытайда вакцина ясаучылар да күп. Моңа җаваплы карыйлар.

Кытайдан кайткач, күңелсез булды, ди Рүзәл. Максат-хыяллары зурдан булган. Коронавирус шул яктан гына тискәре тәэсир иткән. Шулай да югалып калмаган: филологиядән IT-өлкәгә күчкән. Хәзер шул өлкәдә эшли.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Минтимер ШӘЙМИЕВ, Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе:

Социаль челтәрләрдә, виртуаль дөньяда яши торган яшь буын өчен бу, мөгаен, шактый сәер яңгырыйдыр, әмма миңа кулга тотып, чын газеталар, журналлар, китаплар уку ошый. Безнең буын шулай гадәтләнгән өчен генә түгел. Чөнки кулга китап тоту ыгы-зыгыдан читләшергә, игътибарны тупларга мөмкинлек бирә.

(«Татарстан» журналында басылган әңгәмәсеннән)

РОССИЯ ШӘҺӘРЛӘРЕНДӘ – ХЕЗМӘТ ХАКЫ

Казандагы зур һәм урта предприятиеләрдәге уртача хезмәт хакының күләме 54 мең сумга җиткән. Бу узган елгыдан 12,3 процентка күбрәк, дип хәбәр итә башкала мэриясе. Мәскәү һәм Санкт-Петербургны исәпкә алмыйча төзелгән исемлектә Казан иң зур шәһәрләрдәге хезмәт хакы күләме буенча 6 нчы урынга күтәрелгән.



1. Красноярск	62764 сум
2. Екатеринбург	61391 сум
3. Уфа	55722 сум
4. Новосибирск	55438 сум
5. Түбән Новгород	55198 сум
6. Казан	54000 сум

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АКШ – КЫТАЙ: ДУСЛЫКНЫ ЯҢАРТУ

Глобаль сәясәттә һәм икътисадта аек акыл белән аңлау кыен булган вакыйгалар тезмәсе дәвам итә. Соңгы көннәрдә Австрия армиясе Европада масштаблы ут өзелү булырга мөмкинлеген хәбәр итеп, халыкны кисәтте һәм «Б» планына әзерләнергә чакырды. Кибетләр эшләүдән туктаса, ике атнага җитәрлек запаслар җыеп куярга өндәде. Исемлектә фонарьлар, шәмнәр һәм батарейкалардан тыш, бер кешегә көнгә ике литрдан исәпләнгән су да бар. Автомобиль баклары ягулык белән тулы булырга тиеш. Гадәттән тыш хәлнең ни сәбәпле туарга ихтимал икәнлеге әйтелми. Аңлашыла инде: мондый хәл зур табигый катастрофа яисә сугыш шартларында гына оешырга мөмкин. Икенчесе өчен планетада инде өлгереп җиткән төбәкләр бар. Шундый төбәкләрнең берсе – Тайвань. Кытай армиясе ачыктан-ачык Тайваньны чин иленә кушарга җыена. Аның юлына Вашингтонда каршы төшәләр. Океан артындагылар инде булачак сугышка үзләренә аркадашлар да әзерләделәр. Бөекбритания һәм Австралия, АКШ белән өчпочмак төзеп, Тайвань ягында сугышта катнашырга тиеш дип санала башлады.

Атна башында Пекин Австралияне булачак сугышка кысылудан кисәтте. Кытай лидеры «Твиттер»да, Тайвань ягыннан сугышка керсәләр, «австралиялеләрне зур һөҗүм көтә» дип куркытты.

Дүшәмбе көнне Байден белән Си Цзиньпин виртуаль очрашу үткәрделәр. Бу сөйләшүгә ике як та зур өметләр баглады. Һәр ике тараф та үз фикерен өстен чыгарырга омтыла иде. Сөйләшү алдыннан Вашингтонда Кытайны «кагыйдәләр буенча уйнарга чакырачакларын» игълан иткәннәр иде, әмма зур нәтиҗәләргә ирешеп булмаячагын да искәрттеләр. Кытай газетасы «Global Times» та: «Тайвань мәсьәләсе – Кытай өчен төп кызыл сызык», – дип язып, американнарга төп уен кагыйдәсен аңлатты. Сөйләшүдә төп темалар дөнья базарындагы үзара көндәшлек булырга тиеш иде. Америкалылар Кытайның үзләренең төп партнерларына басым ясавыннан зарланды, максатлары шул басымны туктату иде.

Кытай белән югары дәрәҗәдәге сөйләшүләр алып бару читен хәзер, чөнки лидерлары инде ике ел чит илләргә чыкмыйча качып яши. Әмма бу Пекинга үз линиясен үткәрергә бик комачауламый. Алар зур хәрби куәт туплады соңгы елларда. Дөньядагы иң зур Америка хәрби флоты үзенең 490 хәрби корабы, 2600дән артык самолеты, 347 меңнән артык хәрби диңгезчесе белән котчыккыч зур көч тәшкил итсә дә, әлегә аның белән тиңләшә алмый торган Кытай флоты да зур тизлектә үсә. Белгечләр, Далянь һәм Шанхай верфьларында очкыч йөртүче кораблар күз алдында үсеп чыгалар, дип таң калалар. Бүген үк Тайваньга десант төшерерлек мөмкинлеге булмаса да, Кытай моны якындагы елларда эшли алачак, дигән фикер әйтәләр. Дүшәмбе виртуаль очрашуында ике ил лидерлары конфликттан баш тарту турында килештеләр, дигән рәсми сүзләр ишетелде. Рәсми булмаган мәгълүмат кыры, Байден Тайваньның Кытайныкы икәнен таныды, дигән сүзләр дә таратты. Бу шулай булса, планетаның иң куркыныч бер төбәгендә киеренкелек тукталып торачак. Зур янгын куркынычы Европада гына кала. Шулай булгач, Австрия армиясенең зур «блэкаут» белән кисәтүе гаҗәп түгел. Тик бу төбәктә дә сәясәтчеләрнең аек акылы өстен чыгар дип өметләник. Зур конфликт белән янау халыкларның игътибарын үзәккә үткән проблемалардан читкә юнәлтү өчен генә булсын һәм ул куркыту стадиясеннән узмасын иде инде.

Россиядә

КӨМЕШКӘ АППАРАТЫН ТЫЯРГА, НЕФТЬЧЕЛӘРГӘ АКЧА БҮЛӘРГӘ

Россиянең эчке яңалыклары бюджет-финанс мәсьәләләре тирәсендә бөтерелә. Алдагы елларга бюджет «бәлеш»ен бүлешү бара чөнки. «Бәлеш»не зурайту буенча идеяләр туплана, лоббилар кисәкләрнең зуррагын үзләренә тартып алу өчен көрәш алып баралар.

Төп процент ставкасы киләчәктә дә үсәчәк. Үзәк банк рәисе Нәбиуллина ханым, Думага килеп, шул хакта әйтте, чөнки кешеләр «инфляциядән куркалар», диде. Кешеләр куркалардыр да, ә менә инфляция төп ставканың күтәрелүеннән бик курыкмый бугай, чөнки бәяләр һаман үсә. Дәүләт банкларының ипотека ставкасын күтәрүләре дә әлегә төзелеш базарына зур йогынты ясамады кебек. Материалларга бәяләр печтек кенә түбәнәйсә дә, бу – мөгаен, сезонлы түбәнәю генәдер.

Менә шундый шартларда кайбер сәясәтчеләрнең башына аракыдан күбрәк табыш алу идеясе керде. Аракыны QR-код белән генә сату фикере дә чагылып алды берара. Әмма кешеләр көмешкәгә күчәчәк. Әле болай да өйдә көмешкә куу чәчәк ата. Код кертсәң, ниләр буласын чамаларлык та түгел. Шикәрне кодласаң гына инде. Төп идея исә менә болайрак формалаша: аракының бәясен күтәрергә, әмма сатуны арттырырга. Моның өчен көмешкә аппаратларын тыярга. Көмешкә куу бюджетка бер елга йөз миллиард сум зыян китерә дип исәплиләр Федерация Советында. Тыюны кертеп була ул үзе, әмма «Колач җитмәстәйне колачлап булмый» дигән Кузьма Прутков законы үз көчендә кала барыбер.

Бюджет дигәннән, бюджетка иң зур зыянны бензин бәяләре сала бүген. Россиядә бит «демпферлау механизмы» дигән нәрсә үз көчендә. Аек акылга бик үк буйсынып бетми торган ул нәрсә, бензинның экспорт бәясе эчке бәядән ашып киткәндә, нефтьчеләргә югалтуларын компенсацияләүне күз алдында тота. Хәзерге шартларда нефть бәяләре үсүгә бәйле рәвештә дөнья базарында мотор ягулыгына бәяләр арта. Илнең эчке базарында тышкы базардагыдан калыша. Дөрес, безнең хезмәт хакларыбыз һәм пенсияләребез дә бик калыша чит илләрдәгедән. Шулай булгач, бензин бәясенең бездә түбәнрәк булырга тиешлеге аңлашылып тора инде. Әмма югары җитәкчелек аңламый моны. Зур бер түрә әле берничә көн элек кенә бездә бензин 65 сум торырга тиеш дигән сүз ычкындырды. Бензинны шул бәягә күтәрмәс өчен, нефтьчеләргә бюджеттан түләргә туры килә. Бу компенсация алдагы елларда югары белем системасына бюджеттан бүленгән акчага якынлашачак, ә торак-коммуналь хуҗалык чыгымнарын ике тапкыр диярлек узып китәчәк икән. Кайчандыр демпферлау механизмы да булмавын, бензинның да ике тапкыр диярлек арзан торуын оныталар безнекеләр. Хәер, бюджеттан түләнүгә карамастан, бензин бәясе үсә. Быел ул 3,2 сумга арткан.

Дәүләт Советында

ҖИДЕ КАТ ТӨЗӘТ, БЕР КАТ КИС

Депутатлар Бюджет, салым һәм финанс комитеты утырышында бюджетка төзәтмәләрне карап, Дәүләт Советына «2022 елга һәм пландагы 2023, 2024 еллар чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проектын икенче, өченче укылышларда кабул итәргә тәкъдим итте. Шулай ук халыкның финанс белемен үстерү программасын үтәү мәсьәләсе каралды. Комитет утырышы эшендә Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Юрий Камалтынов катнашты.

Комитет рәисе Леонид Якунин әйтүенчә, закон проекты беренче укылышта кабул ителгәннән соң комитетка 533 төзәтмә кергән. Хөкүмәттә аларның барысы да җентекләп тикшерелгән. Кайберләре буенча инде карарлар да кабул ителгән, министрлыклар һәм ведомстволарга тиешле бурычлар йөкләнгән. Хөкүмәт әзерләгән төзәтмәләрдә юл хуҗалыгын, авылларны үстерүгә, урманчылык өлкәсенә өстәмә акча, укытучыларга сыйныфны җитәкләгән өчен айлык түләү, торак төзелешенә, су объектларын саклау программасын гамәлгә ашыруга акча күздә тотылган. Министрлар Кабинетыннан – 498, КПРФ фракциясеннән – 21, Бюджет, салым һәм финанс комитетыннан 13 төзәтмә алынган.

Министрлар Кабинеты төзәтмәләре буенча (498 төзәтмә) финанс министры Радик Гайзатуллин чыгыш ясады. «Төзәтмәләрнең чынбарлыктагы саны – 50, калганнары берсен берсе кабатлый», – диде ул. Министр әйтүенчә, төзәтмәләр нәтиҗәсендә 2022 елга республика бюджеты керемнәренең гомуми күләме – 300 миллиард 32 миллион сум, чыгымнарның гомуми күләме 324 миллиард 46 миллион сум тәшкил итә. Бюджет дефициты – 24 миллиард 13,7 миллион сум. Инде алдан әйтеп үтелгәнчә, комитет бюджет турында закон проектына төзәтмәләрне хуплап, Дәүләт Советына аны икенче һәм өченче укылышларда кабул итәргә тәкъдим итте.

Депутатлар «2022 елга һәм пландагы 2023, 2024 еллар чорына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында» закон проектын да хуплады.

БЕРНӘРСӘ ДӘ ҮЗГӘРМӘЯЧӘК

ДӘҮЛӘТ АРХИВЫ КҮЧЕНҮГӘ КАГЫЛЫШЛЫ СОРАУЛАРГА АЧЫКЛЫК КЕРТТЕЛӘР

Татарстан Дәүләт архивы күченә. Әлеге хәбәр татар җәмәгатьчелеген кузгатып җибәрде. Министрлар Кабинетында узган очрашуда әлеге мәсьәләгә кагылышлы барлык сорауларга Татарстанның Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе Гөлнара Габдрахманова һәм Татарстан дәүләт архивы директоры Илдар Шәфыйков ачыклык кертте.

«Татар-информ»

Росреестрның кәгазь документларын саклау өчен махсуслашкан биналар төзү карары моннан берничә ел ук кабул ителгән булган. Татарстанда яңа бинага урын Казан читендәге Столбище бистәсе тирәсеннән сайланган. Яңа бинаның мөһимлеге һәм андагы мөмкинлекләр хакында Гөлнара Габдрахманова болай аңлатты:

– Әлеге вакытка кадәр дәүләт архивы карамагында биш бина бар иде. Аның Кремль урамындагысы авария хәлендә. Ә Себер тракты (аудиовизуаль документлар) һәм 8 Март урамындагы архивлар 120–150 процентка тулы. Аңлашылганча, безгә яңа бина бик кирәк иде. Архивларның каладан читтә урнашуы да яңалык түгел. Мисалга Самара, Красногорскидагы федераль архивларны китерергә була. Ә яңа бина безгә архив шәһәрчеге булдыру мөмкинлеген бирә. Аның тирә-ягындагы мәйданы да, үзенең гомуми мәйданы да (23697,2 кв. м) зур. Чагыштыру өчен: безнең барлык биш бинаның мәйданы 16 мең квадрат метрны тәшкил итә иде. Яңа мөмкинлекләргә килгәндә, безнең беренчел кабул итү һәм эшкәртү; генеалогия һәм документларны санлы форматка күчерү үзәкләре барлыкка киләчәк. Яңа бинага «Гасырлар авазы» журналы да күченә. Биредә конференция залы, күргәзмәләр мәйданы, туклану урыны да булачак.

Иң төп сорауларның берсе: 8 Март урамындагы бина кемнең вәкаләтенә күчәчәк? Аңа да ачыклык кертелде. Әлеге бина Казанның муниципаль архивы идарәсенә тапшырылачак. Халыкка уңайлы булсын өчен, гражданнарны кабул итү дә шушында калачак. Халыкның сораулары автомат рәвештә бердәм архив мәгълүмат системасына кертеләчәк. Шулай ук сорауларны Татарстанның «Дәүләт хезмәтләре» порталы яки күпфункцияле үзәкләр аша да юллап булачак. Ә инде уку заллары элеккечә үк, 8 Март урамында урнашкан бинада да, Декабристлар урамындагы 4 нче йортта урнашкан бинада да эшләячәк. Гөлнара Габдрахманова әйтүенчә, халык өчен архив эшчәнлегендә бернәрсә дә үзгәрмәячәк.

Архивка күбрәк нинди сораулар буенча мөрәҗәгать итәләр соң? Белгечләр әйтүенчә, халыкны генеалогия, туган як тарихы, архитектура, шулай ук оешма тарихлары кызыксындыра. Сәяси репрессия, кулаклаштыру вакыйгалары, дин тарихы белән кызыксынучылар да шактый. Шулай да, генеалогиягә кагылышлы документлар, болар – метрика, ревизия кенәгәләре – әйләнештә иң күп йөргәннәре. Шуңа күрә алар санлы рәвешкә күчерелгән дә инде. Ә иң аз соралган документлар партия, комсомол документлары икән.

Күченүгә бәйле киңәшмә булгач, архивтагы документлар саны турында сорау да бирелде. Татарстанда 6 миллион берәмлек документ саклана, шуларның 23е уникаль, алар арасыннан сигезе Россия архивының уникаль документлары исемлегенә кертелгән. Иң кыйммәтле документ XII гасырга карый. Әлеге документны саклау һәм күчерү бик четерекле, шуңа күрә ул әлегә элеккеге урында саклана.

Дәүләт архивының яңа бинасына күченү исә берничә этаптан торачак. Аның беренчесе 5 ноябрьдә башланган да инде. Әйтүләренчә, ул 10 декабрьдә төгәлләнер дип планлаштырыла. Икенче этап яңа бинада өстәмә җиһазлар урнаштырылгач башланачак. Гөлнара Габдрахманова әйтүенчә, 34 көн эчендә документлар тутырылган 324509 тартманы яңа урынга алып барып урнаштырырга кирәк.

Яңа бинага эшчеләр һәм архив белән кызыксынучылар ничек барып җитәчәк? Әлеге сораугa Гөлнара Габдрахманова: «Хезмәткәрләрне яңа эш урынына алып бару һәм кайтару өчен ике махсус автобус яллaнды. Хәзерге вакытта Столбище тирәсендә автобус, шулай ук электропоезд өчен яңа тукталыш булдыру мәсьәләсе дә өйрәнелә», – дип җавап бирде.

Илдар Шәфыйков архивның яңа проектлары белән таныштырды. Аның берсе – «Ядкәр» генеалогия порталы. Әлеге порталда архив документларындагы 111718560 язма эшкәртелгәннән соң, Татарстанда яшәгән һәр кеше үзенең шәҗәрәсен өеннән чыкмыйча да төзи алачак. Билгеле, әби-бабалары Татарстан территориясендә яшәгән очракта. Әлегә 40000 язма эшкәртелгән.

Сүз уңаеннан, Гөлнара Габдрахманова Татарстан Президенты исеменә җәмәгатьчелек язган хат уңаеннан да үз фикерен белдерде:

– Архив хезмәткәрләре җентекләп өйрәнергә яраталар. Шуңа күрә без бу хатны да җентекләп өйрәндек. Шуннан чыгып түбәндәге фикерләр белән бүлешәбез. Хат язган кешеләрдән 120се – 1986 елдан алып бүгенгә кадәрге вакыт аралыгында архивта бер тапкыр булган. Башкалары бер тапкыр да килеп карамаган. Архивта эшли дип әйтеп була торганнары – 52.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

«БЕР БАЛА ДА УРАМДА КАЛМАС»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Танышларым арасында берсе дә тәкъдим ителгән тулай торакка бармады. Шартлар монда да яхшы түгел иде. Ләкин хәзер безгә тагын да начаррак урыннарда яшәргә туры киләчәк, диделәр. Анда хәтта кайнар су да юк икән... Әти-әни моннан артык проблема ясады дип әйтеп булмый. Кушканнар икән, димәк, шулай кирәк. Аннан соң мин дүрт ел авылга кайтып эшләү шарты белән укыйм һәм аена 10 мең сум акча алам. Шулай ук уку йорты 2 мең сум стипендия бирә. Шулай булгач, түләргә артык авыр булыр дип уйламыйм. Дөрес, чыгымнар шактый артачак хәзер. Монда тулай торак уку йорты янында гына иде. Хәзер автобуста йөрисе булачак, – диде Илдус.

– Аның каравы киләсе елда матур, заманча бинада яшәячәксез, – дигән сүзебезгә каршы егетләр:

– Белмим, фатирдан кире тулай торакка кайтасы килерме икән? – дип җавап бирделәр.

Матурлык өчен түзәргә туры киләчәк

Әлеге мәсьәлә буенча без университет җитәкчелегенә дә чыктык. Проректор Наил Хәмидуллин әйтүенчә, төзекләндерү – уку йорты өчен күптән көтелгән һәм бик кирәкле эш.

– Әлеге тулай торак күптән төзелгән. Мин бу уку йортын 1984 елда тәмамладым. Шуннан бирле капиталь ремонт күрмәгән бина инде ул. Хәзерге заман таләпләренә бөтенләй туры килми. Балаларны анда яшәтү хәтта куркыныч та. Шуңа күрә без Татарстан Президентына финанслау сорап мөрәҗәгать иттек. Бюджеттан акча бүленеп биргәч, эшкә тотындык. Бер яктан, шатлыклы күренеш бит инде. Киләсе елда университет 100 еллыгын каршы ала. Аңа кадәр ремонтны бетерергә тырышырбыз. Икенче яктан, менә шундый авырлыклар барлыгын да беләбез, – диде ул.

Дөрес, әлегә авырлыклар булса да, киләчәктә студентлар матур, уңайлы шартларда яшәячәк.

– Әти-әниләр көн саен диярлек шалтырата. Аларга да: «Бераз гына сабыр итегез инде», – дибез. Киләсе уку елына кадәр түзсәләр, балалар менә дигән шартларда яшәячәк, – ди Наил Хәмидуллин.

Студентларга урыннар тәкъдим итү мәсьәләсенә килгәндә, монда да аларның мәнфәгатьләрен кайгыртабыз, ди ул.

– Бер бала да урамда калмаячак. Һәркайсының кайда урнашуын, ничек яшәвен белешеп торачакбыз. Яшәү шартлары начар булса, яхшырак урын табарга ярдәм итәрбез. Дөрес, үзебез максатчан укыткан студентларга аерым мөнәсәбәт булыр. Өстенлекләр дә биреләчәк. Студентларның күпчелеген өч тулай торакка урнаштырдык. Калганнары фатир арендалап тора. Аларга да фатир табарга булыштык. Яшәргә урын таба алмаганнарны акрынлап башка уку йортларының тулай торакларына урнаштырачакбыз. Шушы бер-ике көн эчендә анысын да хәл итеп бетерәчәкбез, – диде Наил Хәмидуллин.

Аның әйтүенчә, икенче уку елына тулай торак бинасы бөтенләй танымаслык булып үзгәрәчәк. Тышкы ягы матурланачак, тәрәзә, ишек, җиһазлар, су, электр челтәрләре алыштырылачак.

– Әти-әниләрнең дә хәлен аңлыйбыз. Безнең студентларның барысы да диярлек – авыл балалары. Бик авыр икән инде, ректорат хәл иткән очракта, бәлки ниндидер матди ярдәм күрсәтү турында да уйларбыз. Ләкин безнең башка юл юк. Тулай торак җитди үзгәрешләр кичерәчәк. Берни дә эшләп булмый. Киләчәктә матур, уңайлы булсын өчен, барыбызга да вакытлыча булган авырлыкларга түзәргә туры киләчәк, – дип хәлне аңлатты проректор.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе Алсу Мөхәммәтова әйтүенчә, республикадагы Әлмәт нефть институтыннан кала башка уку йортлары барысы да федераль вузлар булып санала.

– Шуңа күрә бу мәсьәләне бары тик аграр университет җитәкчелеге генә хәл итә ала. Без студентларга тулай тораклар тәкъдим итә алмыйбыз, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

МИЛЛИОНЕР НИКИТА ҺӘМ БАШКАЛАР

«ОЗЫН ТӘНӘФЕС»ТӘН ТАТАРСТАН УКУЧЫЛАРЫ 6 МИЛЛИОН СУМ АКЧА ЭШЛӘП КАЙТТЫ

Безнекеләрне бел!

Кырымның «Артек» яшьләр үзәгендә 8–10 сыйныф укучылары арасында «Озын тәнәфес» Бөтенроссия конкурсының финалы узды. Безнең яшьләр анда 6 миллион сум акча отты. Җиңүчеләрне аэропортта Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов каршы алды.

«Озын тәнәфес» «Мәгариф» илкүләм проекты кысасында тормышка ашырыла. Бәйгенең икенче сезоны март аенда башланган иде. Быелгы сезонның үзенчәлеге дә бар. Анда көллият, техникум студентларына да катнашу мөмкинлеге бирелгән. Татарстаннан барлыгы 80 мең гариза кабул ителгән. Әлеге акчаны югары белем, компьютер алуга, мәгариф курсына тотарга мөмкин. Вузга кергәндә, җиңүченең казанышларына 5 балл өстәлә.

– Бу – зур шатлык! Без һәр катнашучы, җиңүче белән горурланабыз. Аларның уңышлы киләчәгенә ышанабыз! «Зур тәнәфес» ул – бәйге генә түгел, бөтен илдәге сәләтле яшьләрне берләштерә торган бер хәрәкәт. Алар берберсе белән танышалар, бер-берсеннән үрнәк алалар, көч туплыйлар, – диде Тимур Сөләйманов.

Җиңү әҗерсез түгел. Яшьләр барлыгы 6 миллион сум акча откан. Әйтик, 8–9 сыйныфтагы биш укучыга – 200әр мең, ә биш 10–11 нчы сыйныф укучысына миллион сум бирелгән. 8–9 сыйныф укучылары арасында 78 нче лицейдан Элина Абдуллина, Камилә Юнысова, Казанның 121 нче лицееннан Камилә Якупова, 83 нче лицейдан Эвелина Хәйруллина һәм Казан (Идел буе) федераль университетының «IT лицей» укучысы Даниил Савинов катнашкан. Югары сыйныф укучылары арасында «йолдыз»лар – Казан «Галактика» белем бирү үзәгенең 35 нче лицееннан Лиана Мәрданова, 152 нче гимназиядән Алена Баргилова, 19 нчы гимназиядән Алия Латыйпова, 83 нче лицейдан Руслан Әхмәтов һәм Әгерҗе шәһәренең 4 нче мәктәбеннән Никита Филиппов.

– Бәйгедә икенче тапкыр катнаштым. Бу юлы миллион сум оттым. Бик нык сөендем. Әти-әнием, мәктәбем өчен дә зур горурлык бит бу. Укытучыларым проектлар әзерләргә булышты. Акчаны декабрьдә бирергә вәгъдә итәләр. Аны югары белемгә яки уку курслары сатып алуга тотачакмын. Бу бәйге март аенда башланды. Беренче этап читтән торып үткәрелде. Үзең турында видео җибәрергә, биремнәр чишәргә кирәк иде. Мин массакүләм мәгълүмат чараларына багышланган сорауларны сайладым. Журналист булырга җыенмасам да, әлеге тема ничектер күңелгә якынрак. Ярымфинал Казанда Универсиада авылында үтте. Анда инде беренче этап биремнәрен уңышлы башкаручылар җыелып, команда белән экологиягә бәйле сорауларга җавап бирдек. «Артек»та уздырылган финалда сораулар кечкенә җирлекләрне үстерүгә багышланган иде, – дип сөйләде 11 нче сыйныф укучысы Никита Филиппов бәйге турында.

Никита мәктәптә «5ле»гә генә укый. Бигрәк тә тарих, җәмгыять белеме кебек фәннәр белән кызыксына. Дәүләт идарәсе юнәлеше буенча укырга җыена. «Бәлкем, Казанда калырмын, әмма югарырак үрмәлисе килә – Мәскәүгә китәргә теләр идем», – диде ул. БДИга карата

фикере исә бер төрле генә түгел. Имтиханга әзерләнү – укучылар өчен зур киеренкелек. Никита бердәм дәүләт имтиханнарын белем сыйфатын бәяләү системасы дип санаса да, яңа форма кертүне кулайрак күрә.

Сәрия МИФТАХОВА

pixabay.com

ҖИР ШАРЫН ҮЗГӘРТКӘН «ТУГАН КӨН»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Каршы килүчеләр юк»

Азия илләрендәге халык хәзер ничегрәк яши? Чир аларның тормышын ни дәрәҗәдә үзгәрткән?

Илфат Вәлиев Кытайның көньягында – Гуанчжоу провинциясенең Фошань шәһәрендә яши. Кытайга күченгәненә биш ел икән инде. «Бирелә халык чир чорында да, хәзер дә үзен бик тыныч тота», – ди ул. Вазгыятьне барысы да аңлый, хөкүмәткә ышаныч бар, кушылганны үтиләр.

– Тормыш әллә ни үзгәрде дип тә булмый инде. Кытай ябык. Элекке шикелле Азия илләренә чыгып, ял итәргә китеп булмый. Киткән очракта да, кире кайткач, карантин шартларын үтисе. Карантинда утыру бик кыйммәткә төшә. Кытайда вируслар гел булып тора.

> Коронавируска кадәр дә битлектән йөрделәр. Ул – монда гадәти күренеш. Россиядәге шикелле: «Һәр көнне битлек киясеме инде?» – дип уфтану юк.

Узган җәй халык, яллардан файдаланып, тегендә-монда чыгып йөри башлады. Вирус ачыклангач, Гуанчжоу белән Фошаньне икесен дә яптылар. 18 млн кешенең барысына да бер атнада тест уздырдылар, – ди ул.

Чикләүләр димәктән, сәүдә үзәкләренә керү өчен битлек таләп ителә икән. Кинотеатрларга да битлексез йөреп булмый. Кайбер җәмәгать урыннарында һәм транспортта QR-код сорала. «Татарстанда да шундый таләп кертергә җыеналар икән бит. Сездә халык каршы тора. Ә бит сездә кешеләр шулкадәр күп авырый, бу – мәҗбүри чара» – дип аңлата Илфат.

Статистикага карасаң, Кытай вакцина ясаучылар буенча алдынгылар рәтендә тора. «Мин дә, танышларым да вакцина ясаттык. Ясатмаган кешеләрне кулдагы бармаклар белән генә дә санап чыгарга була», – ди Илфат.

7 еллап Кытайда яшәүче Дарья «коронавирус башкаласы» Ухань шәһәренә язмыш шуклыгы белән килеп эләгә, дисәң дә буладыр. Монда озакка калырга уйламаса да, коронавирус башлангач, шәһәр ябылгач, башка чарасы булмый.

– Чаншу шәһәренә эшкә чакырдылар, шунда китәргә тиеш идем. 23 гыйнварда Ухань шәһәрендә Кытайча Яңа елны билгеләп үтәрмен дә, әйберләремне җыеп, Чаншуга күченермен дип хыялландым. Уханьга килеп төшүгә, шәһәрне яптылар. Күңелсезрәк булды инде. Бераз елап, моңсуланып йөрдем дә калган вакытны үземә багышларга булдым. Белем алдым, өстәмә дипломлы булдым, – дип искә ала ул.

Дарья сүзләренчә, аннан күп очракта Кытайда вакцина ясату мәсьәләсе турында сорашалар икән.

– Кытайда өч төрле вакцина тәкъдим итәләр: 1, 2 һәм 3әр дозалы. Элегрәк җирле халыкка да, чит илдән килүчеләргә дә вакцина бушлай иде. Хәзер исә чит ил кешеләре өчен ул түләүле – бер дозасы 69 юань (781,54 сум. – **Ред.**), – дип аңлатты ул. – Уханьдагылар вакцинага карата тискәре караштa түгел. Киресенчә, алар чиргә каршы прививканы бик көтте. Кабат чирләү, тагын бер тапкыр карантинда утыру, эшсез калу куркыныч.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТОТЫЛГАНЫ ДА КЕСӘНЕ ТИШӘ

Машина базары

Очсызлануын көтәргә кирәкми. Яңа ел алдыннан машина бәяләре бераз төшмәсме дип өметләнгән кешеләргә белгечләр шундый киңәш бирә. Ник дигәндә, ел азагына кадәр яңа машиналар гына түгел, тотылганы да кыйммәтләнүен дәвам иттерәчәк, дип фаразлый алар.

Россиядә машина бәяләренең котырып үсүе турында алдагы саннарыбызда язган идек инде. «Автостат» аналитика үзәге белгече Азат Тимерханов моның төп сәбәбен бүген яңа машиналарның дефицит булуы белән аңлата. «Хәзер җаның теләгән машинаны тиз генә алам димә. Ким дигәндә 2–3 ай көтәргә кирәк. Кытлык машина җыйганда кулланыла торган микрочип кебек детальләр җитмәү аркасында пәйда булды. Нәтиҗәдә дилерларга да азрак машина кайта. Бу исә, үз чиратында, бик зур ажиотаж тудыра һәм машина бәясе артуга китерә. Яңа машиналар янына якын килерлек булмагач, кеше тотылган машиналар арасыннан күңеленә ятышлысын эзли башлый. Сорау зур булгач, аларына да бәя арта», – ди белгеч.

Рәсми саннарга ышансаң, ел башыннан бирле Россиядә тотылган машиналар 20 процентка кыйммәтләнгән инде. Төгәлрәк әйтсәк, гыйнвар – сентябрь аралыгында икенчел базардагы «тимер ат» хаклары уртача 150 мең сумга артып, 838 мең сумга җиткән. Kia, Volkswagen, Hyundai машиналары аеруча кыйммәтләнгән. Ел азагына кадәр тотылган машина хаклары тагын 10 процентка артачак, дип фаразлый белгечләр. «Елныңелында шул хәл: Яңа ел алдыннан кеше азмы-күпме җыелган акчасын кая да булса урнаштыру ягын карый. Күпләр машинасын алыштырып калырга тырыша. Күреп торасыз: хәзер өр-яңа машина алу күпләрнең көченнән килми. Шуңа тотылган машиналарга сорау артты да. Сатып алучылар күбрәк бер генә хуҗасы булган, 1–2 еллык машиналарга өстенлек бирә», – ди озак еллардан бирле тотылган машиналар сату-алу белән шөгыльләнүче Илнар Гарәфиев.

Кагыйдә буларак, мондый шаукым вакытында алдану очраклары да еш күзәтелә. Тотылган машина сатып алганда ярык тагарак янында калмас өчен түбәндәге кагыйдәләрне истә тотарга кирәк, ди белгечләр.

КЕМНӘН АЛЫРГА? Алыпсатарлар тәкъдим иткән машиналар арасында юл һәлакәтенә эләккәннән соң төзәтелгән, спидометр күрсәткечләре киметелгән, залогта булган автомобильләр күбрәк очрый.

ТАРИХЫ НИНДИ? Машинаның теркәлү (СТС), транспорт чарасының паспорт (ПТС), идентификация (VIN) номерлары буена машинаның үткәнен өйдән чыкмыйча да тикшереп була. Моны ЮХИДИ идарәсенең рәсми сайтында, махсус онлайн сервисларда эшләп була.


Илдар Мөхәммәтҗанов

МАШИНА КУЗОВЫ НИ ХӘЛДӘ?
Кайчак андагы кимчелекләрне сукыр күз белән дә танып була. Яньчелгән, кителгән, күгәргән, төсе аерылып торган урыннар әллә кайдан күзгә ташлана. Кузовтагы детальләр, тоташтыручы болтлар арасындагы ялганган урыннарга игътибар итегез. Ул бераз ярылган, кәкрәйгән булса, машинаның бәрелгән яки аңа сыйфатсыз ремонт ясалган булуы ихтимал. Бер тапкыр да сүтелмәгән болтта сыдырылган, кителгән эзләр булмый. Моннан тыш машинаның ишекләре, бензин багы капкачы, багажник – барысы да җиңел ачылып ябылырга тиеш. Машина кузовын тикшергәндә, бамперга сугып карарга да онытмагыз. Ят тавыш ишетелсә, анда сынган, «ямалган» урыннар бар дигән сүз.

ДВИГАТЕЛЬ ӘЙБӘТ ЭШЛИМЕ?
Сез алачак машинаның капот асты коры булырга тиеш. Мотор бүлеге ялтырап торыр дәрәҗәгә җиткәнче чистартылган булса, шикләнергә җирлек бар. Двигательнең өзек-өзек эшләве, ят тавышлар, күксел яки кара төтен чыгаруы – тагын бер кат уйлану, йә булмаса машинаның бәясен төшерү өчен бер сәбәп.

МАШИНА НИЧЕК ЙӨРИ? Яшерен-батырын түгел, безнең юлларда машинаны «шалтыратмый» гына йөртү мөмкин түгел. «Тимер ат»ның рычаг, амортизатор өлешләре, гадәттә, иң беренчеләрдән булып сафтан чыга. Тотылган машинадагы бу детальләрнең ни рәвешле эшләвен тикшерү өчен, машинада йөреп карагыз.

САЛОНДА ТӘРТИПМЕ? Биредәге пластмасс өслекләрдә кыршылган, ярылган урыннар булу сатучы файдасына түгел. Педаль һәм рульдәге кыршылган эзләр машинаның күптәннән файдаланылуы турында сөйли. Утыргычлары тузган булса, әлеге «тимер ат» такси булып хезмәт иткән булырга бик мөмкин.

БӘЯНЕ НИЧЕК КИЛЕШТЕРЕРГӘ?
Тотылган машина бер кимчелексез була алмый. Кулдан машина сатып алган кешегә бары тик игътибарлырак булып, җитешсезлекләрен күрергә генә өйрәнергә кирәк. Бу машинаның үз бәясенә торырлыкмы-юкмы икәнлеген чамаларга ярдәм итәчәк, алданырга да ирек бирмәячәк. Аның бәясен килешкәндә дә җайлы булачак. Сатып алгач, машинага өстәмә ремонт таләп ителү, тышкы (бәрелгән, сынган, буялган урыннар булу, тәрәзә чистарткычлар эшләмәү һ.б.) һәм эчке (салонның пычрак, таушалган булуы һ.б.) кимчелекләр – болар бар да машина бәясен төшертергә мөмкинлек бирә. Хәтта машинаның запас ачкычлары булмаган өчен дә бәя төшерүне сорый аласыз.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЭШМӘКӘР ЭДУАРД БАСЫЙРОВ:

«90 МЕҢ ДОЛЛАРНЫ СУГА САЛДЫМ»

Суд залыннан

Соңгы вакытларда шәхси байлыгын төрле юллар белән чит илләргә чыгаручылар күбәйгән. Татарстан таможнясы хезмәткәрләренә дә закон бозучылар белән әледән-әле эш итәргә туры килә. Статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, чик аша чыкканда закон бозулар узган елның шул чоры белән чагыштырганда 14 процентка арткан.

Илнең Стратегик эшләнмәләр үзәге баш белгече Наталья Сафина әйтүенчә, Россиядә 2021 елның өченче кварталында чик аша законсыз чыгарылган байлык күләме дүрт тапкыр арткан. Закон бозуларның күпчелеге чик аша акча һәм кыйммәтле әйберләр алып чыгуга карый. Гамәлдәге закон буенча ул 10 мең доллар белән чикләнгән булса да, кайберәүләр Остап Бендердан да уздырып, яшерен кесәләр яисә чемодан төпләрендә һаман күбрәк күләмдә байлык алып чыгу юлларын эзли.

– 2014 елда ил җитәкчесе Владимир Путинның офшор зоналарына кагылышлы мәгълүм карарыннан соң, чит илләргә чыгарылучы капитал ташкыны шактый кимегән иде. Акча чыгаруны чикләү башлыча Евразия икътисади берлегенә керүче илләргә кагылды. Беларусь, Әрмәнстан, Казахстан һәм Кыргызстан кебек илләргә чыгарылучы капитал күләмен чикләү кертелмәгән. Күпләр шуннан файдаланып калырга омтыла. Соңгы ун елда читкә чыгарылган капитал күләме якынча исәпләүләр буенча 613 миллиард долларга җитә, – ди Наталья Сафина.

Белмәгәннең дә башы авырта

Россия һава юллары, аерым алганда, Габдулла Тукай исемендәге Казан Халыкара аэропортының таможня хезмәте аша кыйммәтле әйберләр, чикләнгән суммадан дистәләрчә тапкыр күбрәк акча алып чыгарга омтылучылар да шактый икән.

«Татар-информ»

Югыйсә декларациядә күрсәтелмәгән ювелир эшләнмәләр, сәнгать әсәрләре, алтын-көмеш һәм башка төр кыйммәтле әйберләрне төрле яшерен юллар белән чик аша чыгарырга теләүчеләр контроль хезмәтенең заманча техника һәм технологияләрдән файдалануын да яхшы белә. Андыйлар быел да йөзләрчә миллион сумлык байлыгыннан мәхрүм калган. Өстәвенә 7 миллион сум штраф түләттерелгән.

Казан эшмәкәре Эдуард Басыйров белән Лаеш районы суд залында очраштык. «Туксан мең долларны суга салдым», – дип сыкрана ул.

Тикшерү материалларыннан күренгәнчә, эшмәкәр ниндидер ашыгыч эш белән Казан аэропортыннан Төркиянең Истанбул шәһәренә очарга ниятли. Билгеләнгән вакытта «яшел зона»ны үтеп, «кызыл зона»дагы контроль-тикшерү бүлегенә үтә.

Биредә җиһазландырылган махсус стендларда пассажирның таможня аша күпме акча алып чыгу мөмкинлеге зур хәрефләр белән язылган. Стендларда эре хәрефләр белән һәр пассажирның үзе белән алып чыгасы акча һәм башка кыйммәтле әйберләрнең бәясе 10 мең доллардан артырга тиеш түгеллеге дә күрсәтелгән. Шуңа да хөкемдарлар Эдуард Басыйровның: «Мин бу турыда белмәдем», – дип акланырга маташуын нигезле дип тапмады. Өстәвенә, чит ил паспортындагы тамгаларына караганда, гаепләнүченең Төркиягә беренче баруы гына түгел икән. Тикшерүчеләр аның 2021 елда Төркиягә биш тапкыр сәфәр кылуын ачыклаган.

Тәҗрибәле эшмәкәр чит илгә зур күләмдә акча алып чыгуның башка юллары барлыгын да белгәндер. Әмма офшор яки таможня берлегенә керүче илләр аша эш иткәндә дә читкә чыгарылучы байлыкның каян килүе белән кызыксынучы махсус органнарның төрле сорауларына җавап бирергә уңайсызланган булса кирәк. Озак еллар җаваплы эшләрдә эшләгән, хезмәт хакы да артык зур булмаган кешегә андый сорауларга җавап табу җиңел түгелдер шул.

Таможня хезмәткәре Евгений Анисимов әйтүенчә, «Казан – Истанбул» рейсына утырырга җыенучы пассажирлар «Хайскан» махсус контроль җиһазлары аша күзәтү уза. Алып чыгасы әйберләр дә өйрәтелгән этләр ярдәмендә тикшерелә. Яшерелгән акча булса, ул шунда ук ачыклана.

Акланырлык сәбәп юк

«Кызыл зона»да эшләүче башка хезмәткәрләр дә Эдуард Басыйровның чик аша зур күләмдә акча алып чыгарга омтылуын ялгышлык белән түгел, ә таможня хезмәтенең аның бу гамәлен күрми калуына өметләнеп эшләнгән дип саный.

Сер түгел, тикшерүчеләр төп игътибарларын беренче чиратта пассажирның үзе белән яисә багажында наркотик матдәләр, корал яки башка куркыныч әйберләрне ачыклауга юнәлтә. Ә инде чемодан, рюкзак, сумка, барсетка һәм башка төенчекләр, пассажирларда ризасызлык тудырмас өчен, җиңелчә генә тикшерелә. Эдуард Басыйров та шуңа өмет иткән булса кирәк. Таможня хезмәткәрләре рюкзак төбендәге калын китап эчендә махсус урын ясап урнаштырылган 90 мең долларны табып ала.

Мондый гамәл өчен, Россия Федерациясе Җинаять кодексының 200.1 нче маддәнең 2 нче бүлегендә әйтелгәнчә, закон бозучыны бер елга ирегеннән мәхрүм итү каралган.

Җаен туры китереп, эшмәкәрнең ни сәбәпле бу адымга баруын сораштырдым. Газетадан икәнлегемне белгәч, дөресен әйтергә булды. Төркиядә аның берничә йорты бар икән. Шуларны Россиядән ял итәргә баручы туристларга арендага биреп, акча эшли ул. Соңгы вакытларда Россиядән туристлар ташкыны бермә-бер арткан. Шуңа да 90 мең долларга тагын бер йорт сатып алмакчы булган. Тиз арада эләктереп калмаса, башкалар алачак. «Шулкадәр акчаны суга салу – минем өчен зур фаҗига», – дип уфтана эшмәкәр.

Суд барышында Эдуард Басыйров төрле сәбәпләр табып, никадәр генә үзен акларга тырышса да, барып чыкмады. Лаеш районы суды карары нигезендә чик аша рөхсәт ителгән суммадан тугыз тапкыр күбрәк акча алып чыгарга маташканы өчен гаепле дип табылды. Акча дәүләт файдасына алынды.

Суд шулай ук Эдуард Басыйровның бер елга ирегеннән чикләү турында карар кабул итте. Бу вакыт эчендә эшмәкәр үзе яшәгән территориядән читкә чыкмаска, махсус күзәтү органнарында ай саен теркәлү узарга тиеш булачак.

Камил СӘГЪДӘТШИН

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Бикколов** Илдар Шамил улы, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе президенты **Гортышов** Юрий Федорович, Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты Икътисади анализ идарәсе баш киңәшчесе **Зәйнуллина** Светлана Фәрхәт кызы, хезмәт ветераны **Рахманов** Илдус Васил улы, «Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе генераль директоры **Руденко** Гөлзадә Рәкыйп кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Бәдретдинова** Чулпан Мөнир кызына; «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе артисты **Малинин** Александр Вячеславовичка; «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе артисты **Скрябин** Илья Николаевичка; «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе оркестры артисты **Туктамышев** Назар Рөстәм улына; вокалчы артист (солист), шәхси эшкуар **Сафиуллин** Илназ Зиннур улына; «Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең бию ансамбле балет артисты **Хөсәенов** Илнар Хәмит улына; «Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең «Идел егетләре» фольклор ансамбле вокалчы артисты (солисты) **Биктимеров** Альберт Рәшит улына; вокалчы артист (солист) **Рәхимова** Динара Зиннур кызына; «Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең «Идел егетләре» фольклор ансамбле солисты-инструменталисты **Шәфиев** Рамил Наил улына; «Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Хәйретдинова** Эльвира Мулланур кызына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, озак еллар буе агросәнәгать комплексы өлкәсендә эшләгән

НӘБИУЛЛИН
Габделхак Мирзагабдулла улы

кинәт вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 «Ватаным Татарстан»ның «ВКонтакте» төркеменә язылырга һәм мини-трактор уйнату турындагы хәбәргә репост ясарга. Яки «ВТ»ның «Инстаграм» сәхифәсенә язылырга, бәйге турында «Актуаль»дәге соңгы постны скриншот ясап, «ВТ»ның аккаунтын билгеләп, үзеңә урнаштырырга.

3 Язылу квитанциясен һәм «Инстаграм» яки «ВКонтакте» аккаунтыгызның сылтамасын безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче җирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, җирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН:** **vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә	465 сум	П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә	1000,92 сум

Реклама 16+

Реклама

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

ПАРЛЫ ГОМЕР

Соклану

Кукмара районының Әсән-Елга авылына килеп чыккач, иң беренче танышкан кешеләремнең берсе Габделхак абый Габделхәев булды. Авылның барлыгын, бөтенлеген, тарихын саклап калу өчен мәш килеп йөри торган тиктормас кеше ул. Култык астында папка, анда күбесе кәгазь кисәкләреннән генә торган «вакытлыча документлар»; соңрак аларны берләштергән дәфтәрләр дә шунда урын алган. Яңа мәчет төзелеше буенча да, авылдагы үлем-җитем, туучылар буенча да көндәлек алып барылган. Кыскасы, авыл халкы өчен менә дигән елъязмачы инде.

Сөйләшә торгач, шунысы да ачыкланды: мактанырлыклары да, горурланырлыклары да бар икән тугызынчы дистәне ваклаган Габделхәевләрнең. Шулай булмыйни! Әсән-Елгада Люция апа белән иң озак парлы гомер кичерүче гаилә икән бит алар. Аз да түгел, күп тә түгел, 61 ел. Дүрт бала үстергәннәр, укытканнар. Бүген уллары Миңнерахман белән киленнәре Минзиләнең кадер-хөрмәтендә яшиләр. Туган җиргә мәхәббәт тәрбияли белгәннәр алар балаларында. Раузалия белән Гүзәлияләре дә авылда төпләнеп калган. Нурияләре генә Арча педагогия училищесын тәмамлаганнан соң юллама белән Тәтеш якларына китеп барган да Апас районының Чирмешән авылы егетен бәхетле иткән. «Еш кайталар, шөкер, – ди Габделхак абый. – Әле машина йөрткәндә үзем дә шунда чыгып китәргә генә тора идем. Сагындыра бит», – дип күз яшьләренә дә ирек биреп алды. Ул ара булмый, хәләл җефетен дә, яшь баланы сөйгәндәй, әрләп алды: «Соңгы вакытларда аяклары авырта әле, и-и, гомер буе фермадан кайтып кермәде инде. Эшкә кертүен үзем керткән идем анысы. Гаеп миндә дә бар. Шул сыерларын яратты да инде түлке. Көннәр буе кайтмыйча ятарга әзер иде. Гел аяк өстендә йөреп, салкын тидереп, аякларына зыян килде, ахры».

Күренеп тора, әрләгәндәй итсә дә, олы бер мәхәббәт белән сөйли Габделхак абый заманында Арпаяз авылыннан урлап кайткан Люциясе турында. Кичке уеннарда таныша егет белән кыз. Үз авылларында да сүз салучы егетләр була Люциягә. Әмма күрше авыл егетен нигәдер якынрак күрә шул. Егет тә төшеп калганнардан түгел. Ятып калганчы, атып калыйм, дигәндер инде, кызга тәкъдим ясый. Люция риза, тик менә әнисен ничек күндерергә? Укытучы Нисаның бердәнбер кызы бит ул. Әтисе сугышта ятып калды. Укытасы килә шул әнисенең. «Кияү качмый ул, укырга кирәк», – дигән сүзләрне дә еш әйткәли. Икәүләп уйлашалар да, алдан сөйләшеп, Габделхак Люцияне урлап китәргә була. Икенче көнне әнисенә: «Кызыгыз бездә», – дигән хәбәр җиткерәләр. Арпаяз бригадирын иптәшкә алып, җил-җил килеп җитә Ниса апа. Әмма аларны капка төбендә колхоз рәисе туктата. «Бер-берсен яраткан парны аермагыз», – дип киңәшен бирә. Ярату гына түгел, уңганлыклары белән дә бар кешене сокландыра яшьләр. Бер ел дигәндә шыгырдап торган бүрәнәдән йорт салып, башка да чыгып куялар. Ул арада беренче балалары да дөньяга килә. Габделхакның шәп кияү икәнлеген күргән әнисе үпкәсен бик тиз оныта. Соңгы көннәрдә кызы гаиләсе аның төп терәге була.

Егет гаиләсендә Люцияне дә шикләнеп кенә кабул итәләр анысы. Габделхакның әнисе: «Укытучы кешенең бердәнбер кызы инде, улым. Авыл эшенә ярамас, иркәләп кенә үстергәндер», – дигән сүзләр дә ычкындыра. Әмма фаразлар туры килми. «Люциям бик батыр, чая булды. Бер эштән дә тарсынмады. Әни белән тату, дус булып, 36 ел гел бергә булдылар. Бер-берсеннән зарланганнарын ишетмәдем», – дип искә ала Габделхак абый. Хәер, Люция үзе дә тормышын яшьтән үк авыл белән бәйли. Пычак авылында җиденчене тәмамлагач, Кукмарада бер ел укый да, әнисенең ай-ваена карамастан, фермага эшкә кайта. Башта малларга бәрәңге пешерә, аннары сыер саварга керешә. «Иртән дүрттә эшне башлый идек, – ди ул. – Бер кеше унбишәр сыер саудык. Таңнан торып эшкә йөрү җиңел түгел иде анысы. Әмма сынатырга уемда да юк иде. Зарлана белмәдем». Габделхак абый, хисләргә бирелеп, үзем керттем фермага, дип хафаланса да, Люция апа, кияүгә чыккач, эшен дәвам гына иткән булып чыкты. 12 ел сыер сава ул Әсән-Елгада. Аннан терлекләргә азык әзерли: сенаж чокырына салынган яшел үләнне көннәр буе балта белән чаба, ат арбасына төйи. Таналар, бозаулар да үстерә. Бозауларга сөт ташып эчерә, тирес чыгара. Хатын-кыз өчен үтә дә авыр эш, әмма китү турында уйлап та карамый. Күп еллар «таяк»ка эшли. Яхшы хезмәте өчен медаль белән бүләкләнә.

Габделхак абыйның да әтисе сугыш кырында ятып кала. 12 яшьтән җигелеп тормыш арбасын тарта башлый. Үгез белән басу-кырларны сукалау дисеңме, ат белән урман чыгару, колхозга ашлык, ягулык ташу – берсе дә калмый. «Тормыш бик авыр булды, – ди ул. – Ашарга такы-токы, ягарга утын юк, кием-салым да бер чама гына. Хәтерлим әле: өйдәге салкынга чыдап булмагач, колхоз өендә 3–4әр гаилә бергә куна идек. Бил бөктек, авырлыклар күрдек, әмма чыдам, нык булдык без».

Кичке мәктәптә машина йөртү таныклыгы алгач, колхозга шофер булып урнаша Габделхак. Ферма мөдире, бригадир булып эшләгән чаклары да була. Әнә шулай, авылдан читкә китмичә, туган җиргә хезмәт итеп, 1995 елны икесе дә лаеклы ялга чыгалар.

Әмма йомшак мендәргә баш төртеп, дөнья мәшәкатьләреннән баш тартып, картларча ял итү турында уйлап караганнары да юк әле. «Барыбыз бергә җыелганда, өебез гөр килеп тора», – ди алар. Чыннан да, күбәү бит: 4 бала, килен-кияүләр, 9 онык, 11 оныкчык... Һәркайсы белән гәпләшеп алыйм гына дисәң дә, санаулы ял көннәре җитеп бетмәс. Икәү генә калган чакларында бергәләп телевизор карап, газета-журналлар укып алалар, тәмле ашлар пешереп, терлек-туар караган чаклары да күп була. Җәй көннәрендә бакчада җиләк-җимеш, яшелчә үстерәләр. Әби белән бабайның эшгамәлләре үз ихаталарына гына сыеп бетми. Әйткәнемчә, бөтен яңалыкны барлыйсы, авыл халкына ирештерәсе, тарихка кертеп калдырасы бар. Монысын да бергәләп эшли алар. Саваплы эш тукталып кына калмасын, дәвамчылары гына булсын инде.

Габделхак абыйның зур проблемалар күтәрергә дә көченнән килә әле. Район газетасында басылган «Сугыш ятимнәре гел читтә кала» дип аталган мәкаләсе – шуларның берсе. «Әтиләре сугыштан исән кайтканнарны бәхет басты: фатирлы да, машиналы да булдылар. Күпсенеп әйтүем түгел. Бар да җитә, шөкер. Әмма шул ук вакытта әтисез үскән сугыш ятимнәрен бүгенгә кадәр искә алучы да юк, – ди ул. – Әле ярый узган ел Җиңү бәйрәмендә мәктәп укучылары капкага кызыл чәчәк кадап киттеләр. Гомер буена шушы җиргә хезмәт ителгән бит. Кайдан булса да берәр котлау открыткасы җибәрсәләр дә, күңел булыр иде».

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ПЕТР ЗАЙЦЕВ:
«БЕЗНЕҢ ӨЙДӘ БАР ДА ТАЛЧЫБЫКТАН»

Зәйдә яшәүче Петр Зайцев кул эшләренә бик оста. Гомере буе машина йөртүче булып эшләсә дә, башка шөгыльләргә дә вакыт тапкан. Лаеклы ялга чыккач, талдан кәрҗин үрү эшенә ныклап алынган.

– Минем бабаем, әтием бик тә кул эшләренә оста иде. Аларның талдан үргәннәрен күреп, мин дә бу эшкә өйрәндем. Баштарак әлбәттә, барып та чыкмый иде. Әмма чыбыкларны сындыра-сындыра, эшкә өйрәндем инде. Хәзер үрә башласам, күңелем ял итә. Бер кәрҗин үрүгә ике сәгать вакыт җитә, – ди ул. Петр Михайлович бар эшенә көч биреп торучы Надеждасына рәхмәтле. Инде гаилә коруларына да 48 ел икән. Өч бала үстергәннәр, 6 онык, 4 оныкчыклары бар. Петр Зайцев үз белгәннәрен хәзер оныкларына өйрәтә.

– Һәрнәрсәгә теләк кирәк. Әгәр эшкә булдырам дип тотынгасың икән, ул килеп чыга. Берәү дә эшне белеп тумый. Кулың эш белү – зур бәхет. Бездә бөтен савытлар тал чыбыгыннан. Хәзерге пластик әйберләрне алган да юк. Ипи, җиләк-җимеш, гөл савытларының барысын да үз кулларым белән үрдем. Юасы керләр өчен дигән кәрҗинем дә бар. Җиләккә, гөмбәгә бара торганнары да җитәрлек. Мин аларны сатмыйм. Якыннарыма, дусларыма бүләк итәм, – ди ул.

Петр дәдәй хатыны белән бергә җиләк, гөмбә җыярга бик һәвәсләр. Җәйләрен болыннан кайтып та кермибез, диләр. Хуҗалар өйдә вакытта бу йорттан кунак өзелми.

– Туганнарыбыз белән төрле бәйрәмнәрдә бергә җыелышып утырабыз. Рус халкының мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклыйбыз. Аларны балаларга өйрәтәбез. Оныклар да читтә калмый. Кәрҗин үрергә өйрәткәндә, гореф-гадәт тә искә алына. Әгәр шулай эшләмәсәң, киләчәк буын милләте хакында берни белмәячәк, – ди Петр Зайцев. – Татарстанда яшәгәч, без күршебезнең дә гореф-гадәтләрен белергә тиеш. Бу яктан мин бәхетле. Татарча да өйрәндем. Бик яхшы сөйләшә алмасам да, аңлыйм. Бер-береңне хөрмәт итсәң, дус яшисең. Менә шушы сүзләрне һәр ата-ана, әби-бабай балаларга җиткерсен иде. Яшь буынны хезмәткә өйрәтеп, шөгыльле итеп үстерергә кирәген дә онытмыйк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7404 данә
Гомуми тираж – 17211 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 367

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+